**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** Казан ш. **БОЕРЫК**

_31.03.2022 __236-п____

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы каршындагы гомумтаралган файдалы казылма һәм җир асты сулары запаслары буенча республика комиссиясе турында» 2021 елның 1 июлендәге 739-п номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының норматив хокукый актларын гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы каршындагы гомумтаралган файдалы казылма һәм җир асты сулары запаслары буенча республика комиссиясе турында» 2021 елның 1 июлендәге 739-п номерлы боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Боерыкның преамбуласын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы Россия Федерациясе Законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Файдалы казылмалар һәм җир асты сулары запасларына дәүләт экспертизасы турында, файдалануга тапшырыла торган җир асты байлыклары кишәрлекләре турында геологик мәгълүмат һәм аны биргән өчен алына торган түләү күләме һәм бу түләүне алу тәртибе турында» 2005 елның 11 февралендәге 69 номерлы карары, Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының «Каты файдалы казылмалар запасларын исәпләү буенча дәүләт экспертизасына тапшырыла торган материалларның составына һәм рәсмиләштерү кагыйдәләренә карата таләпләр раслау турында» 2011 елның 23 маендагы 378 номерлы боерыгы, «Татарстан Республикасында җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2022 елның 25 февралендәге 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 06 июлендәге 325 номерлы карары белән

расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы турындагы нигезләмә нигезендә боерык бирәм:»;

«Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы каршындагы гомумтаралган файдалы казылма һәм җир асты сулары запаслары буенча республика комиссиясе турында» нигезләмәнең 1.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Республика комиссиясе үзенең эшчәнлегендә «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы Россия Федерациясе Законына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Файдалы казылмалар һәм җир асты сулары запасларына дәүләт экспертизасы турында, файдалануга тапшырыла торган җир асты байлыклары кишәрлекләре турында геологик мәгълүмат һәм аны биргән өчен алына торган түләү күләме һәм бу түләүне алу тәртибе турында» 2005 елның 11 февралендәге 69 номерлы карарына, Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының «Каты файдалы казылмалар запасларын исәпләү буенча дәүләт экспертизасына тапшырыла торган материалларның составына һәм рәсмиләштерү кагыйдәләренә карата таләпләр раслау турында» 2011 елның 23 маендагы 378 номерлы боерыгына, «Татарстан Республикасында җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2022 елның 25 февралендәге 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсенә кагыла торган башка норматив хокукый актларына, әлеге Нигезләмәгә таянып эш итә.»;

4.6 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:
«- комиссия утырышында җаваплы сәркатип булмаган очракта, комиссия әгъзалары арасыннан җаваплы сәркатипне билгели.».

Министр А. В. Шадриков